ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

04.05.2022 ел Баулы шәһәре №77

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасы буенча торак сатып алу (төзү) хокукы турында таныклык бирү һәм исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы 2021 елның 30 декабрендәге 244нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасы буенча торак сатып алу (төзү) хокукы турында таныклык бирү һәм исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы 2021 елның 30 декабрендәге 244нче карарына үзгәрешләр кертергә:

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән» сүзләрен преамбулада төшереп калдырырга;

“Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү" ярдәмче программасы буенча торак сатып алу (төзү) өчен социаль түләү алу хокукы турында таныклыкны исәпкә кую һәм бирү буенча административ регламентта:

2нче «муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» бүлегендә:

2.5.1. пунктында.:

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә «5) чит ил дәүләтенең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык һәм аларны нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемә итү (булганда)»;

түбәндәге эчтәлекле 10) пункт өстәргә:

10) Граждан хәле актларын теркәү органнары яисә Россия Федерациясе консуллык учреждениеләре тарафыннан бирелгән уллыкка алу турында таныклыклар»;

Егерменче абзац: «5) ипотека торак кредиты (займ) чараларын кулланып сатып алынган (төзелгән) торак бинага милек хокукын дәүләт теркәве турында таныклык күчермәсе яисә күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (торак йортны тәмамламаган төзегәндә подпрограмманың дәүләт заказчысы тарафыннан расланган төзелешкә документлар тапшырыла)";

пункт 2.6.1. дополнить подпунктами 4), 5) и 6) следующего содержания:

«4) сведения о постановке на учет в налоговом органе физического лица (ИНН) - Федеральная налоговая служба России;

6) - 8) пунктчаларны 5) - 7) пунктча дип санарга;

2.6.1. пунктны 4), 5) һәм 6) түбәндәге эчтәлекле 4 пунктчалар өстәргә:

4) физик затның (ИНН) салым органында исәпкә кую турында мәгълүматлар - Россия Федераль салым хезмәте;

5) күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрыннан аның булган күчемсез милек объектларына хокуклары турында, Россия Федерациясе территориясендә аларны читләштерү буенча алыш-бирешләрне гамәлгә ашыру турында күчермәсе - Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе;

6) гаиләнең һәр балигъ булмаган һәр әгъзасына индивидуаль шәхси счетның (СНИЛС) иминият номеры турында белешмәләр - Россия Федерациясе Пенсия фонды.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе — И.И. Гузаиров